# «Чык тамчысы»

**МАДОУ**

**Детский сад №49**
**«Росинка»**

***Апрель, 2022 ел***

## 1 нче апрель- Көлке көне белән!




1 нче апрель - Көлке көне,
Белмәсәгез – белегез.
Мәшәкатьләрне онытып,
Рәхәтләнеп көлегез!

Көлү – арганны бетерә,
Кан әйләнешен көйли.
Хәтта, гомерне озайта –
Табиблар шулай сөйли!

3 минуты – 15 минут
Физик хезмәт шикелле.
Уйнап-көлеп яшәүчеләр
Әнә ничек сөйкемле!






## Бакчабызда - Рус халык әкияте көне!

Әкият – халык авыз иҗатының бик борынгы жанры. Ул – тылсым һәм могҗизалы уйдырмага нигезләнгән, яки маҗаралы һәм гадәттән тыш хәлләргә-вакыйгаларга корылган фантастик әсәр.

Беренчедән әкиятләр халык авыз иҗатының иң “озын гомерле” төрләреннән берсе булып санала. Икенчедән, әкиятләргә гадилек хас. Әкиятнең эчтәлеге, аерым мотивлары, образлары, күренешләре ничек кенә маҗаралы булса да, әкиятнең төзелеш композициясе бик гади.Өченчедән, әкиятнең ничек башланасын, дәвам итәсен һәм ничек тәмамлануын һәр кеше диярлек белеп тора.

Нинди генә тәрбия чарасы әкият, җырлы - биюле яисә хәрәкәтле уеннардан башка үтә микән?Безнең дә тәрбиячеләребез шул юнәлештә тырышып эшлиләр һәм “Рус халык әкияте” көнен балалар белән бик теләп искә алдылар.Балалар белән кызык эчтәлекле, шул ук вакытта мавыктыргыч булган әкият геройлары белән якыннан таныштылар. Бакчабызда тәрбияләнүче балалар киләчәктә лаеклы кешеләр булыр дип ышанабыз!








# Хәрәкәттә - бәрәкәт!



**Саулык - иң зур байлык!**
**(Татар халык мәкале)**

Безне,балаларны,сәламәт рухта тәрбияләү – бүгенге көн таләпләреннән иң мөһиме, чөнки безнең күп вакыт балалар бакчасы, мәктәптә уза.Шуңа күрә сәламәтлекне саклау, ныгыту, физик үсешне тәэмин итү буенча һәрьяклап эшләргә кирәк. Юкка гына халык “Сәламәт тәндә – сәламәт акыл” димәгән.



“Кеше үзенең тәнен көчле, сәламәт итеп тәрбияли алса, ул тормыш авырлыкларына да каршы тора ала.Сәламәтлек, чыдамлылык, яшәү өчен көч һәм энергия запасы стрессларга һәм тормыштагы кыенлыкларга каршы көрәшү өчен төп корал булып тора” – дип яза күренекле галим Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. Әйе, сәламәтлек – иң зур байлык. Балалар һәм яшүсмерләр дә, укытучылар һәм әти-әниләр дә шушы байлыкка ирешү, аны саклау, үстерү, ныгыту алымнарын, ысулларын яхшы белергә, көндәлек тормышта шуларны гамәлгә ашырга барырга тиеш.

Сәламәтлек көненә бакчабызда да зур әһәмият бирелә. Ел саен үткәрелә торган бу бәйрәм көне - традициябезгә әйләнеп бара.Без бакчабызда тәрбияләнүче балалар белән иртәнге гимнастика , төрле уеннар, флеш-моблар үткәрәбез, вакытыбызны һәрьяклап файдалы, мавыктыргыч итеп уздырабыз. Көндәлек режимны төгәл үтәгәндә генә сәламәтлегебез тагын да ныгыр, таза, көчле булырбыз!



Әле шуны да әйтеп узырга кирәк бакчабыздан Эльвира Хайдарова Россия күләм “Тормышка мең адым” акциясендә катнашып тәненә сихәт, көч - куәт алып кайтты.



# 12 нче апрель – Космонавтика көне!



1961 елның 12 апрелендә иртәнге 9 сәгать 7 минутта Казах ССР далаларда урнашкан Байконур космодромыннан галәмгә ракета җибәрелә. Әлеге ракетада Беренче космонавтлар төркеме әгъзасы – 27 яшьлек Юрий Гагарин була. Ул дөньяда беренче булып ачык галәмгә чыга һәм йолдызларга таба юл сала.


Космонавтика көне балалар күңелендә зур кызыксыну тудыра. Уз күзләре белән рәсемнәрдән күреп, ишетеп, кечкенә куллары белән, күңелләрендә булган хисләрен ак кәгазь битенә бик шатланып төшерәләр, аннан сөйләп бирәләр. Бакчабыздагы хәр төркемдә бик зур эш алып барыла.

Бакчабызда бер бәйрәм дә ихътибарсыз калмый. Космонавтика көне уңаеннан зур гына күргәзмә дә оештырылды.Барлык төркемнәр дә бик теләп катнаштылар, балалар үзләренең шәхси эшләнмәләрен алып килделәр һәм уртаклаштылар. Шундый сәләтле балаларыбыз булганда бакчабыз тагын да ямьләнер, чәчәк атар!













## Бакчабыз яңалыклары !

Бакчабыз мөдире Хайдарова Рәзинә Госман кызын чын күңелебездән шәһәр башлыгы рәхмәт хаты алуы белән котлыйбыз! Сезгә киләчәктә дә зур уңышлар, яңа үрләр яулавыгызны телибез!Без сезнең белән горурланабыз!




## Кечкенә йолдызчыкларыбыз!

11 нче апрель көнне балалар үзләре өчен зур тәҗрибә туплап, белемнәрен арттырып, үзләрен күрсәтеп, калганнарны карап Брэйн- ринг бәйгесендә катнаштылар. Балаларга, аларны әзерләгән тәрбиячеләргә, әлбәттә эти - әниләребезгә рәхмәтләребезне җиткерәбез. Шушундый тырыш, зирәк, уңган балаларыбыз булганда киләчәгебез якты һәм өметле!





# Мин татарча укыйм!




Татар теле - минем туган телем,
Сөйләшүе рәхәт ул телдә.
Шул тел белән көйлим,
Шул тел белән сөйлим,
Милләттәшем булган һәркемгә!


“Халыкның иң зур байлыгы,иң кадерле рухи хәзинәсе – аның теле. Халык үзенең телен, мең еллар буена үстереп килгән, аны өзлексез баетып, матурлап, иң тирән фикерләрен, иң нечкә хисләрен дә аңлатып бирер дәрәҗәгә җиткергән ” – дигән Гомәр Бәширов. Әйе, бу сүзләр белән килешми булмый. Чөнки туган телебез – безнең өчен иң газиз,иң матур, иң кирәкле тел!

Шунысы куаныч, татар телен саклау һәм үстерү максатыннан Габдулла Тукай исемендәге үзәк китапханәдә 3 нче ел рәттән "Мин татарча укыйм" бәйгесе оештырыла.Бу бәйгедә бакчабыз тәрбиячесе Азизова Гөлнур Зиннәтулла кызы катнашып 3 нче урынга лаек булды.

Шул уңайдан 20 нче апрель көнне Халыклар дуслыгы йортында "Туган тел - туган ил нигезе" исеме астында татарча диктант акциясе узды.Бу акциядә дә Гөлнур Зиннәтулла кызы үзен актив яктан күрсәтте. Афәрин!!! Туган телебезне бергәләп саклыйк, бергәләп яклыйк!











# Безнең уңышларыбыз!

Бакчабызда һәр көн диярлек ниндидер конкурска, бәйгегә катнашуга әзерлек эшләре алып барыла. Менә бүген дә, 20 апрель көнне балалар иҗат фестиваленең сайлап алу этабында "Чык тамчысы"ансамбленә йөрүче балалар Нурзия Мирхазова сүзләре Наилә Яхина көенә язылган "Чигү остасы" җыры белән чыгыш ясадылар.Булдырасыз балалар! Уңышлар сезгә!




# Без - аның белән горурланабыз!

Сүзем - бакчабызда мәктәпкәчә әзерлек төркемендә тәрбияләнүче Хуснутдинов Азат турында. Азат бик күп кенә бәйгеләрдә катнашып бакчабыз данын яклап чыгыш ясады, җиңүгә иреште!

21 нче апрель көнне Алабуга шәһәренең 29 нчы балалар бакчасында " Мин бит татар малае" республикакүләм бәйгесенең финалы узды.Бәйгегә 134 эш кабул ителгән.Шуның 20 се 2 нче турга узган.Алар арасында бакчабызда тәрбияләнүче Хуснутдинов Азат та бар.Азат үз туган телендә шигырь укып, җыр башкарды.Бакчабыз данын яклады.Бу бәйге – балалар, әти-әниләр һәм тәрбиячеләрнең уртак хезмәт нәтиҗәсе. Афәрин Азат!

Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, Габдулла Тукай иҗатына нигезләнгән «Без – Тукай варислары» дип исемләнгән республикакүләм бәйгесенең йомгаклау турында Азатыбыз - “Иң күркәм Тукай варисы” номинациясендә җиңүче булды! Шушындый сәләтле балаларыбыз булганда бакчабыз тагын да яңа үрләр яулар, уңышка ирешер диган теләктә калабыз!







# 26 нчы апрель – Г.Тукай туган көн!


Һәр ел саен язлар җиткәч,
Күңелгә тула бер ямь.
Сандугачым җырлый кебек
Тиздән бәйрәм, зур бәйрәм.
Бәйрәмнең дә нинди бит
Тукай абый туган көн!
Илгә даһи, бөек шәхес
Олуг шагыйрь килгән көн.

Бакчабызда бөек шагыйребез Габдулла Тукай туган көненә багышланган " Тукай эзләре буйлап" әдәби- музыкаль чара узды. Әйе, һәр ел саен сагынып көтеп алабыз бу көнне.Тукаебызнын шигырьләрен, хикәяләрен бик яратып укыйбыз,сәхнәләштерәбез, беркайчан онытмыйбыз!


Бөтен дөнья бәйрәм итә
Аның туган көнендә.
Кырлаеннан килә Шүрәлесе
Су анасы чыга бу көндә.











Газета 49 нчы балалар бакчасының 10 нчы төркем тарафыннан чыгарылды.

**Тәрбияче – Азизова Гөлнур Зиннәтулла кызы.**